**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«11» апрель 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Абрыскино авыл җирлегендә 24.11.2023 ел, № 4 гражданнар җыены карары турында карарның аны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Абрыскино авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2024 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: Х.Х.Хәмидуллин

Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Хәмидуллин